**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 2 июлендәге 2305 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 22 маендагы 1584 номерлы**
**«Казан шәһәре территориясендә стационар булмаган**
**сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында»гы**
**карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.33, 39.36 статьялары, 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы «Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында»гы карары (аңа Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 октябрендәге 732 номерлы, 2017 елның 18 сентябрендәге 675 номерлы, 2019 елның 17 июнендәге 498 номерлы, 2020 елның 29 декабрендәге 1221 номерлы, 2023 елның 13 гыйнварындагы 4 номерлы, 2023 елның 18 августындагы 985 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), Казан шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 25 апрелендәге 1417 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 22 маендагы 1584 номерлы «Казан шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында»гы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 13 августындагы 2617 номерлы карары

белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. таблицадан түбәндәге эчтәлекле юлларны төшереп калдырырга:

| № т/б | Реестр номеры | Факттагы адресы | Факт буенча профиле | Мәйданы, кв.м |
|---|---|---|---|---|
| «46 | А-90 | Побежимов урамы, 83 номерлы йорт янында | Азык-төлек | 25 тән артык түгел» |
| «54 | А-120 | Челюскин урамы, 40/15 номерлы йорт янында | Азык-төлек | 85 тән артык түгел» |
| «58 | А-133 | Совет урамы, 90 номерлы йорт янында (Кадыш торак массивы) | Автомобильләр өчен товарлар | 20 дән артык түгел» |
| «170 | К-76 | Фрунзе урамы, 1 номерлы йорт янында | Азык-төлек | 60 тан артык түгел» |
| «389 | П-12 | Комиссар Габишев урамы, 4 номерлы йорт янында | Чәчәкләр | 20 дән артык түгел» |
| «462 | П-116 | Техника урамы, 39а номерлы йорт янында | Азык-төлек | 20 дән артык түгел» |
| «510 | П-182 | Детский юлы, 1 номерлы йорт янында | Азык-төлек | 60 тан артык түгел |
| 511 | С-2 | 2 нче Азино урамы, 41 номерлы йорт янында | Чәчәкләр | 30 дан артык түгел» |

1.2. таблицаның «Авиатөзелеш районы» бүлегендә:

1.2.1. 57 нче юлны түбәндәге редакциядә бирергә:

| № т/б | Реестр номеры | Факттагы адресы | Факт буенча профиле | Мәйданы, кв.м |
|---|---|---|---|---|
| «57 | А-128 | Максимов урамы, 47 номерлы йорт янында | Азык-төлек булмаган- | 60 тан артык түгел» |

1.2.2. түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| № т/б | Реестр номеры | Факттагы адресы | Факт буенча профиле | Мәйданы, кв.м |
|---|---|---|---|---|
| «70(1) | А-149 | Үзәк Мариуполь урамы, 112/28 номерлы йорт янында | Азык-төлек | 60 тан артык түгел |
| 70(2) | А-150 | Үзәк Мариуполь урамы, 110/29 номерлы йорт янында | Азык-төлек | 60 тан артык түгел |
| 70(3) | А-151 | Гудованцев урамы, 130 номерлы йорт янында | Азык-төлек | 200 дән артык түгел |
| 70(4) | А-152 | Гудованцев урамы, 130 номерлы йорт янында | Җәмәгать туклануы | 200 дән артык түгел» |

1.3. таблицаның «Вахитов районы» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| № т/б | Реестр номеры | Факттагы адресы | Факт буенча профиле | Мәйданы, кв.м |
|---|---|---|---|---|
| «130(1) | В-81 | Эш Урам урамы, 8 номерлы йорт янында | Автомобильләр өчен товарлар | 50 дән артык түгел» |

1.4. таблицаның «Идел буе районы» бүлегендә 509 нчы юлны түбәндәге редакциядә бирергә:

| №<br>т/б | Реестр<br>номеры | Факттагы адресы | Факт буенча<br>профиле | Мәйданы,<br>кв.м |
|---|---|---|---|---|
| «509 | П-181 | Профессор Камай урамы, 1 номерлы йорт янында | Азык-төлек | 60 тан артык түгел» |

1.5. таблицаның «Совет районы» бүлегендә 642 нче юлны түбәндәге редакциядә бирергә:

| №<br>т/б | Реестр<br>номеры | Факттагы адресы | Факт буенча<br>профиле | Мәйданы,<br>кв.м |
|---|---|---|---|---|
| «642 | С-224 | Совет урамы, 19 номерлы йорт янында | Икмәк-күмәч ризыклары | 12 дән артык түгел» |

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**